Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Ямбакты авыл җирлеге Башкарма комитеты

# КАРАР

17.02.2023 ел №5

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Ямбакты авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 10 сентябрендәге 22 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Ямбакты авыл җирлеге территориясен планлаштыру документларын әзерләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм "Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында" Федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацының үз көчен югалтуын тану хакында 2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, ТР Спас муниципаль районының Ямбакты авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Ямбакты авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 10 сентябрендәге 22 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Ямбакты авыл җирлеге территориясен планлаштыру документларын әзерләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.12 пунктында "бер ай һәм өч айдан артык" сүзләрен "ундүрт көн һәм утыздан артык көн" сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2023 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Спас муниципаль районының рәсми сайтында "Интернет" мәгълүмат-коммуникация челтәрендә spasskiy.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Ямбакты авыл җирлеге
башкарма җитәкчесе И.Ә.Гәләветдинов.

